ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 15 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2025, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 4 пунктындагы беренче абзацта «бер үк диндәге» сүзләрен төшереп калдырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Үзәкләштерелгән дини оешма башка үзәкләштерелгән дини оешма тарафыннан төзелергә мөмкин.»;

2) 12 статьяның 2 пунктында:
а) өченче абзацта «максатлары» сүзен «предметы, максатлары» сүзләренә алмаштырырга;
б) алтынчы абзацка «һәм алардан файдалану юнәлешләре» сүзләрен өстәргә;

3) 26 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«26 статья. **Дини оешмаларның керем китерә торган эшчәнлеге**

Дини оешмалар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә керем китерә торган эшчәнлекне башкарырга хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 25 апрель
№ 24-ТРЗ